# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Халыкны эш белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт фондына кертемнәрнең 1993 елның икенче яртысында иминлек тарифы турында

I статья. Халыкны эш белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт фондына кертемнәрнең 1993 елның икенче яртысында иминлек тарифы, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм хуҗалык итүче башка субъектлар өчен - төрле яклап исәпләнелгән хезмәт хакына карата 2 процент күләмендә, колхозлар һәм совхозлар өчен I процент дип билгеләргә.

2 статья. Гарипләрнең иҗтимагый оешмалары, әлеге оешмалар милкендә булган һәм барлык табышны гарипләрнең иҗтимагый оешмаларының устав максатларын гамәлгә ашыру өчен тотучы предприятиеләр, берләшмәләр һәм учреждениеләр Халыкны эш белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт фондына иминлек кертемнәре түләүдән азат ителәләр.

3 статья. Күрсәтелгән акчаларның үз вакытында һәм тулысынча түләнүен тикшерүне Дәүләт салым хезмәте һәм Татарстан Республикасы банклары учреждениеләре белән берлектә Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәтенә йөкләргә.

4 статья. Әлеге Законны басылып чыккан мизгеленнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 25 мае